РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 5

2026 елның 28 гыйнвары

## Түбән Кама муниципаль районы Советының хезмәт хакы турында кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәте турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Аеруча әһәмиятле» серлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык процент өстәмәсе күләмен - 50 процент, «бөтенләй яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булганнары өчен - 50 процент, «яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булганнары өчен тикшерү чараларын уздырып рөхсәт рәсмиләштергәндә - 15 процент, тикшерү чараларын уздырмыйча - 10 процент итеп билгеләргә».

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районының бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1 Аерым оешмаларның җитәкчеләренә, белгечләренә, хезмәткәрләренә һәм эшчеләренә «аеруча әһәмиятле» серлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык процент өстәмәсе күләмен - 50 процент, «бөтенләй яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булганнарга - 50 процент, «яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булганнарга тикшерү чараларын үткәреп рөхсәт рәсмиләштергәндә - 15 процент, тикшерү чараларын үткәрмичә - 10 процентны билгеләргә.».

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.И.Беляев